**СОВЕТ ЧЕРЕМУХОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423195, РТ, Новошешминский район, село Слобода Черемуховая, улица Пролетарская, 47

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧЕРЕМУХОВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423195, РТ, Яңа Чишмә районы, Черемухово Бистәсеавылы, Пролетар урамы, 47

тел.:(884348)35-4-17, факс: (8-84348)35-4-17, Cher.Nsm@tatar.ru

КАРАР

2019 елның 29 октябре № 1

"Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Черемухово авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Черемухово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Черемухово авыл җирлеге башлыгы

Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Черемухово авыл җирлегенең Черемухово авылында Заречная урамы буенча 1-26, Набережная урамы буенча 1-26, Октябрьская урамы буенча 1,2,4,6 нче йортларда яшәүче гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын 12 ноябрь көнне сәгать 10.00 сәгатькә Черемухово авылында Набрежная урамы, 10 йорт янында уздырырга дип билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Черемухово авыл җирлегенең Черемухово авылында Малая Зеленая урамы буенча 1-7, Первомайская урамы буенча 2-15, Большая Зеленая урамы буенча 1-11, йортларда яшәүче гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын 12 ноябрь көнне сәгать 14.00 сәгатькә Черемухово авылында Малая Зеленая урамы 6 йорт янында уздырырга дип билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Черемухово авыл җирлегенең Черемухово авылында Совет урамы буенча 57-90 ; Молодежная урамы буенча 1-7, Первомайская урамы буенча 16-26 , Малая Зеленая урамы9-16 йортларында яшәүче гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының өченче этабын 2019 елның 13 ноябрендә сәгать 10.00 сәгатькә Молодежная урам буенча 2 нче йорт янында билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Черемухово авыл җирлегенен Черемухово авылында яшәүче гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының дүртенче этабын 2019 елның 13 ноябрендә 10.00 сәгатькә Черемухово авыл мәдәният йортында (Пролетарская ур., 47 йорт) янында билгеләргә.

5. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Черемухово авыл җирлегенен Черемухово авылында яшәүче гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының бишенче этабын 2019 елның 14 ноябрендә 14.00 сәгатькә Черемухово урта мәктәбендә (Пролетарская ур., 53 А йорт) янында билгеләргә.

6. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Черемухово авыл җирлегенен Черемухово авылында яшәүче гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенының алтынчы этабын 2019 елның 15 ноябрендә 15.00 сәгатькә Закрома " агрофирмасы янында билгеләргә

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2020 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Черемухово авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада укучы студентлар, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары, Чернобыль АЭСдәге һәлакәт нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучы, 1 төркем инвалидлар, картлар һәм инвалидлар интернат йортында яшәүче гражданнардан тыш) 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрү белән килешәсезме:

- юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү););
- урамнарны яктырту лампалары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;;
- су белән тәэмин итү һәм каптаж челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү, су белән тәэмин итү челтәрләренә хезмәт күрсәтү буенча эшләргә түләү;);
- җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- юлларны кардан чистарту.

"РИЗА" "КАРШЫ"

8. Әлеге карарны «Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә).

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Черемухово авыл җирлеге башлыгы Е.А. Сальцина